Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №III-9**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 24 июлендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” XX-10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 17 октябрендәге “Россия Федерациясе Урман кодексының 43 – 46 маддәләре нигезендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган агачны сату Кагыйдәләренә һәм дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сатуны оештыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында" 1341 нче номерлы карарына туры китерү максатларында, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 1 апрелендәге 45-ФЗ номерлы, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнарга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында” XX-10 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 13.12.2017 ел XXIV-3, 04.09.2018 ел XXXIII-5, 24.09.2019 ел XLV-7 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.4. Муниципаль мөлкәтне аукционда сату “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла;

1.2) 5.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.5. Муниципаль мөлкәтне ачык (гавами) тәкъдим ярдәмендә бәяне игълан итмичә сату “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001

елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Г. Әхмәтҗанова